Олы Солтан авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01.2016 г Олы Солтан ав. № _2__

Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару мәсьәләләрен җайга салучы законнарны гамәлгә ашыру чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 431 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында " 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль районга керүче җирлекләрдән мәгълүмат җыю буенча, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле булган хокукый актлар регистрын алып бару өчен кирәкле булган хокукый актлар һәм алар турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы белән төзелгән 2016 елның 29 гыйнварындагы Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актлар һәм алар турында белешмәләр җибәрү буенча эш барышында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгының 2016 елның 29 гыйнварындагы 12пг номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен муниципаль норматив хокукый актларны һәм алар турында белешмәләрне җыю һәм җибәрү буенчаРегламентына таяна.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратына авыл җирлеге Советының, авыл җирлеге башлыгының һәм авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль норматив-хокукый актларын, шулай ук алар турында белешмәләрне регистрга кертелергә тиешле

белешмәләрне җибәрү өчен җаваплы итеп авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре билгеләнә.

3.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ